# НОВОСИБИРСК ТАТАРЛАРЫ

№ 08 (35) август 2022 год

Общественная неполитическая информационная газета ОО «РТНКАНО» и ГБУК НСО «НОТКЦ»



КАЗАНДА ОЧРАШУЛАР - 2 -

ЧТО В «СИБИРСКОМ СУНДУЧКЕ»? - 3 -

«ЧӘК-ЧӘК БӘЙРӘМЕ» - 4 -


# ЙӨЗ ТАПКЫР ИШЕТКӘНЧЕ, БЕР ТАПКЫР КҮРҮЕҢ ЯХШЫРАК

***30 июльдән 2 августка кадәр Казанда Бөтендөнья татар конгрессының VIII Съезды узды. Быелгы съезд Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллыгына багышланды. Кунакчыл Татарстан үз җирендә Россия Федерациясенең 76 төбәгеннән һәм 35 якын һәм ерак чит илдән 1500 делегат һәм шәрәфле кунак кабул итте. Бу чара төрле буын татарларын бер урында берләштерде. Онытылмаслык көннәр татар дөньясына һәм татар теленә чумдырды.***

Мондый чараларда катнашканда мин үземне үз урынымда хис итәм. Көндәлек тормышта миңа бу хисләр җитми. Беренче көнне үк съездның барлык кунаклары Кабан күле яр буенда «Печән базары» фестивалендә катнаштылар. Быел ул унынчы тапкыр узды. Ш. Мәрҗани урамында сәүдә рәтләре тезелеп киткән иде. Бирелә күптәнге танышлар очрашып аралаштылар. Безнең чорда тере аралашу бик җитми. Фестивальнең программасы бай эчтәлекле иде. Һәркем үз кичерешләрен алды. Кызганычка каршы, программада әйтелгәннәрнең барысын да күреп булмады. Тик осталар ярминкәсе дә этник товарларга яңача карарга мөмкинлек бирде. Хәзерге заман ничек гармонияле рәвештә татар гореф-гадәтләре белән үрелгән. Татар орнаментын барлык дизайн әйберләрендә дә күрергә мөмкин иде. Татар дизайнерлары милли үзенчәлекне чагылдырган киемнәрне модага кертүе сөендерми калмый.



*Новосибирск өлкәсенең делегатлары һәм шәрәфле кунаклары*



*Алинә Ермолаева*

***Халыкның милли үзенчәлеген саклап калу өчен иң беренче чиратта үсеп килүче буынны дөрес тәрбияләргә кирәк, диләр. Курчак остасы Алинә Ермолаева да бу авыр мәсьәләдә үз өлешен кертә дип уйлыйм. Нәни кызлар өчен аның үз тылсымлы татар курчаклары бар. Нәкъ менә кызлар — булачак әниләр, гаилә кыйммәтләрен саклаучылар бит.***

Алинәнең бу өлкәдә юлы, күп остабикәләрнеке кебек үк, бала караган ял елларында башланган. Әле мәктәп елларыннан ук, ул, ни булса да эшләргә яраткан. Барлык стеналар да чигелгән картиналар белән тулган иде, дип сөйли. Дуслары декрет ялында йоннан уенчыклар ясарга тәкъдим итә. Ләкин бу эш барып чыкмый. Аннары ул уенчыклар, курчаклар ясый башлый.

— «Печән базары»нда мин инде беренче генә ел катнашмыйм. Фестивальдә катнашу җиңел түгел, катнашу өчен ел саен гаризалар күбәйгәннән күбәя бара. Осталарның эше фестиваль таләпләренә туры килергә тиеш. Милли курчакларны 6-7 ел элек тегә башладым. Лаеш районында «Каравон» фестивалендә катнашу өчен бер татар курчагы, бер рус курчагы тектем. Кешеләрнең алар белән кызыксынуын күрдем. Татар стилендә курчаклар ясап карарга булдым. Шулай ук «Казан сувенирлары» конкурсында катнашып, финалга кадәр барып җиттем. Балалар курчакларыма яхшы тәэсир итүен игътибар иттем. Иң зур илһам чыганагы —балаларның шатлыгын һәм кызыксынуын күрү. Тагын да күбрәк эшлисе килә башлый. Шулай ук, музейга барганнан соң илһамланам. Мәсәлән, узган гасыр башындагы шәһәр татар кызы киемен күреп. Мәктәптәге хезмәт дәресләре дә ярдәм итте дип саныйм. Эксклюзив курчакларыма муенсалар, чулпылар, хәситә ясыйм. Хәзер Татарстан Республикасы Милли музеенда «Идел буе Болгары дәүләте. Бөек мирас» күргәзмәсе ачылды. Анда төрле уникаль костюмнарны, зәркән эшләнмәләрен күрергә була. Шуңа күрә, мондый матурлыкка сокланып кайткач, ничектер алган белемнәрне кулланасы килә башлый, курчакларда көтмәгәндә яңа элементлар пәйда була. Мондый ярминкәләрдән соң, башка шәһәрләрдән килгән кунаклар да Казанның бер өлешен үзләре белән алып китүе бик сөендерә.

> *Без зур үзгәрешләр чорында яшибез, вакыт ут тизлеге белән уза. Мәгълүмат агымына йотлыгасын. Татар матбугаты да заманча тенденцияләрдән калышмый һәм заман белән бергә атлый. Бик күп кызыклы теле-радио проектлар эшләп килә. Тик, кызганычка каршы, рус телендәге тыңдаучылар белән чагыштырганда, боларның барысын да кешеләрнең тар даирәсе генә кабул итәргә мөмкин. Үз укучыңны үстерергә кирәк, дигән уй күп тапкырлар яңгырады. Сер түгел, хәзерге мәгариф системасы милли телләрне үз программасыннан этеп чыгарды диярлек. Язма тел югала, сөйләм теле гадиләшә. «Мин әт кебек барысын да аңлыйм, әмма әйтә алмыйм», дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Ә бит якын киләчәктә андыйлар да калмаска мөмкин. Тел бит ул катлаулы нәрсә. Татар телендә яза, укый һәм уйлый белүчеләр күпме? Бөтен өмет — ата-анада, диләр. Ләкин күп гаиләдә татар теле «киләчәк» сүзе белән рәттән килми. Әле 2000нче елларның башында, хәтерлим, өлкән сыйныф укучылары табигый һәм төгәл фәннәрне рус телендә укытуларын сорадылар. Уку йортларына укырга кергәндә кыенлыклардан куркып. Ә туган телләрендә сөйләшергә оялганнар күпме иде? Рус телен начар белүләрендә туган тел гаепле дип санап. Татар теленең бу хәлдә булуына кем гаепле соң? Тел югалса, балаларыбыз беркайчан да татар әдәбияты, сәнгате һәм халык тарихы дөньясы белән танышмый. Узган гасырда ата-аналарыбыз белән мондый омтылышлар булды инде.*

Ә икенче көнне барлык кунакларны Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгына алып бардылар. 1100 ел элек рәсми рәвештә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгән. Бу татарлар өчен көч урыны. Болгарның ел саен үзгәрүе таң калдыра. Күпме эшләнгән һәм тагын күпме эшләнәчәк. Чөнки тормышка ашыру өчен планнар бик күп икән әле. Бу көннең кульминациясе — Ак мәчет артындагы флешмобта катнашу булды. Оештыручылар катнашучыларга дөрес урыннарга басырга ярдәм итте. Кош очу биеклегеннән «ТАТАРЛАР» сүзен күрергә мөмкин иде. Аннары татар бию көенә биеп тә алдылар. Йомгаклау көнендә әзер видеороликны күргәч, тырышлык бушка булмавын аңладылар. Хәтта каз тәннәре чыкты...

Съездның рәсми өлеше «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәгендә узды. Беренче көнне 7 дискуссион мәйданчык эшләде. «Татар мәгълүмат кыры: алда торган бурычлар» мәйданчыгында Казан һәм Россия төбәкләреннән 60тан артык журналист катнашты. 12 чыгыш булды. Һәр чыгыш ясаучы үз эше турында сөйләде, шәхси тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Мәйданчыкның модераторы Шамил Садыйков доклад вакытында, татар матбугатының киләчәген 4 юнәлештә күрәбез диде. 1) Интернет һәм социаль челтәрләр аша эшләү. 2) Мультимедиа куллану. 3) Кадрлар әзерләү. 4) Маркетплейслар аша тарату. Татар тормышын яктыртучы татар газеталары 15 төбәктә эшли. Аларга ярдәм итү өчен махсус грантлар булдыруны сорады.

Кичке программа кысаларында кунаклар Татарстан Республикасы сәнгать осталары концерты белән хозурланды. Бигрәк тә «Кәләй урамнары» керәшен халык җырын башкарган көчле, моңлы тавыш таң калдырды.


***(ахыры 2нче биттә)***


## *ИХЛАС КҮҢЕЛДӘН КОТЛЫЙБЫЗ!*



**Дания Кабибулла кызы Кусаинова**
**3 августта 20 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.**

Чанов районы Кече Тебис поселогында туган, Новосибирск дәүләт педагогика университетының III курс студенты һәм булачак математика укытучысы. «Алтын йолдыз» татар яшьләр клубы әгъзасы, «Мирас» вокаль ансамбле солисты, күп кенә бард фестивальләре лауреаты, Тубылдагы «Искер җыен» тарихи-мәдәни фестиваленең I дәрәҗә лауреаты. Актив тормыш рәвеше алып бара, волонтер буларак күп эшли.

Сезгә озын-саулыклы гомер, имин-бәрәкәтле тормыш, киләчәк көннәрегезнең өметле булуын телибез!

***Татар автономиясе советы, татар мәдәни үзәге коллективы һәм «Новосибирск татарлары» гәҗите редакциясе***

# ЙӨЗ ТАПКЫР ИШЕТКӘНЧЕ, БЕР ТАПКЫР КҮРҮЕҢ ЯХШЫРАК

*(ахыры, башы 1нче биттә)*

Йомгаклау көнендә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов катнашында съездның пленар утырышы узды. Яңгыраган чыгышлар бик кызыклы һәм кыю булды. Рөстәм Нургалиевич тәнкыйтьне кабул итте һәм үзләренең эшләреннән бик канәгать булмавын



*Болгар шәһәренең «Ак мәчет»е*

әйтте, алда әле күп кенә мәсьәләләрне хәл итү бурычы тора. В.Г. Шәйхразыевка бар да әйбәт дип уйлап, хыялланып китмәскә кушты. Утырышның нәтиҗәсе булып ТР Премьер-министры урынбасары Васил Габтелгаяз улы Шәйхразыевның икенче срокка Милли Шура рәисе итеп сайлануы һәм резолюцияне кабул итү булды. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының яңа составы расланды. Бу исемлеккә Новосибирск өлкәсенең губернатор киңәшчесе, Новосибирск өлкәсенең төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте президенты Гәрәев Әмир Гыймадислам улы да керде.

Съезда катнашучылар белән аралашу вакытында мин төрле хисләр кичердем. Чөнки бу кешеләр үз төбәкләрендә, чын мәгънәсендә, изге эшләр эшлиләр. Минем уйлавымча, аларның эшләре күп җаннарга тынычлык китергән. Бу чарадан соң, нәселгә ачыклык кертү турында уйлар һәм планнар күпләр арасында уянгандыр дип уйлыйм. Шул исәптән минем дә. Күпме үземне хәтерлим, гел фамилиямнең кайдан барлыкка килүе турында сорыйлар. Ачыкларга вакыт. Үткәннән башка киләчәкне төзеп булмый. Һәрберебезнең бу дөньяда үз урыны, үз миссиясе.



*Делегатлар — актив тормыш позицияле кешеләр*

Һичшиксез, съезд йомгаклары турында әле озак сөйләшәчәкләр. Күп нәрсә әйтелде һәм инде цитаталарга таралды. Уңай фикерләр белән янәшә тискәреләре дә бар. Милләтнең бердәмлегенә кадәр, кызганычка каршы, әле бик ерак, дип танырга кирәк. Көчләрне берләштерү урынына, һәркем юрганны үзенә тартырга тырыша. Ни генә булмасын, катнашучылар канатланып, алга таба эшләргә илһамланып киттеләр.

**Равза Тихомирова, Новосибирск өлкә татар мәдәни үзәге директоры, Татарстан Республикасының атказанган артисты һәм мәдәният хезмәткәре, Новосибирск өлкәсенең региональ татар мили-мәдәни автономиясе вице-президенты:**

— Татарларның тарихи җиренә төшкәндә, үзебезнең Татарстан Республикабыз булуына бөтен татарлар өчен горурлык һәм шатлык хисе белән туласың!

Татарстан Республикасы — Россиянең алдынгы һәм икътисадый яктан уңышлы регионы. Күп кенә инновацион проектлар нәкъ менә биредә сынау уза, бу Татарстанда тормышны уңайлы һәм заманча итә. Татарстанда сәнгать һәм авыл хуҗалыгы, мәгариф һәм фән, мәдәният һәм сәнгать, спорт һәм туризм үсеш алган.

Татарстан табигате беренче минутлардан – болыннары, Идел елгасы һәм Чулманның текә ярлары, Чатыртау тавы һәм куе урманнары белән таң калдыра. Республиканың җир асты байлыклары эре нефть ятмаларына бай, бу төбәктә тормышның югары дәрәҗәсен тәэмин итә.

Татарстан — Россиянең спорт йөрәге, биредә ел саен төрле спорт төрләре буенча дөнья чемпионатлары уза. Бу шулай ук туристик яктан иң кызыклы төбәкләрнең берсе. Казанга, Бөек Болгарга һәм Зөя утрау-шәһәрчегенә йөзләрчә мең турист килә.

Новосибирск өлкәсе делегациясе Бөтендөнья татар конгрессының VIII Съезды эшендә катнашу өчен, Татарстан Республикасы башкаласы, 1000 еллык тарихы булган, Казан шәһәрендә булу хөрмәтенә лаек булды. Съезд программасы төрле чаралар белән тулы иде. Кызганычка каршы, без «Печән базары» фестивалендә катнаша алмадык, чөнки безне аэропорттан кунакханәгә соң алып кайттылар, барлык автобуслар да фестивальгә киткән иде, ә без шактый ерак яшәдек. Әмма икенче көнне без борынгы һәм Бөек Болгар шәһәренә, аның тарихи урыннарына һәм искиткеч Ак мәчетенә сокландык. Экскурсияне югары дәрәҗәдә оештырылуын билгеләп үтәсе килә — ул 25 уңайлы туристик автобустан торган кортедж да, беренче затлардан сәламләү белән тантаналы ачылыш та, концерт номерлары да, тарихи урын территориясе буенча танып белү экскурсияләре дә, һәм, әлбәттә, 1500 кунак өчен ачык мәйданда тантаналы төшке аш таң калдырды, анда барысы да каралган һәм лаеклы иде! Өстәләр тәмле ризыклардан сыгылып торды. Киләсе ике көн конгресс эшенә багышланды. Теләге булганнар төрле секциядә катнаша алды, башка төбәкләрдән килгән делегатлар белән танышып, алга таба хезмәттәшлек өчен элемтәләр алышындылар. Без Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы вәкилләре белән аралашып, төбәгебездә иң авыр мәсьәләләр турында фикер алыша алдык.



*Дәүләт символлары белән истәлеккә*

Соңгы көнне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында булдык, анда съездны оештырган өчен барысына да рәхмәт әйтеп, Рәхмәт хатлары һәм бүләкләр тапшырдык. ТР Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе В.Г. Шәйхразыевка — якташыбыз Шамил Рәхимов картинасын бүләк иттек. Соңыннан БТК Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров миңа җыр башкарырга кушты. Минем өчен, әлбәттә, бу көтелмәгән хәл иде, ләкин мин югалып калмадым һәм киңәшмәдә катнашучыларның күбесен елаткан «Әнием» җырын башкардым... Бөтендөнья татар конгрессының төбәкләрдәге Татарстан Республикасының атказанган артистлары турында онытмавын һәм аларны Бөтендөнья татар конгрессының съезды кысаларында булса да, профессиональ концертларда катнашырга чакыруын телибез...

**София Гасанова, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Новосибирск өлкәсенең региональ татар мили-мәдәни автономиясе советы әгъзасы:**

— Новосибирск өлкәсенең региональ татар милли-мәдәни автономиясе әгъзасы буларак, миңа Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездында Новосибирск өлкәсе татарларын тәкъдим итү хөрмәте насыйб булды.

Рәсми өлеш башланырга ике көн кала, делегатларга һәм кунакларга зур мәдәни программа тәкъдим ителде. Бөек Болгарга - барлык татарлар өчен изге урынга бару



*Новосибирск кунаклары Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Габтелгаяз улы Шәйхразыев белән*

миндә онытылмаслык тәэсир калдырды! Халкыбыз өчен көч урыны нәкъ менә биредә дип саныйм! Съездның пленар утырышында Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев чыгышында түбәндәге сүзләрне ишеттем:

*«Карап йөрим изге Болгар җирен,*
*Үткәннәрне укыйм һәр таштан.*
*Болгарның бит монда һәрбер ташы*
*Чал тарихка барып тоташкан.*
*Әсәрләнеп йөрим мин Болгарда —*
*Әйтерсең лә мин үз куышымда.*
*Нәселемнең изге биләве бу,*
*Шәҗәрәмнең башы шушында».*
*(Роберт Миңнуллин)*

Бу шигырь юллары мине гаилә тамырларын өйрәнергә дәртләндерде. Моның өчен мин «Милли үзаңны тәрбияләүдә шәҗәрәнең әһәмияте. Гаиләнең, балалар бакчасы һәм мәгариф системасының роле.» дискуссион мәйданчыгында тәкъдим ителгән интернет ресурсларыннан файдаланачакмын. http://yadkyar.tatar.ru/

Милли үзаң гаиләдән килә дип уйлыйм, татар халык мәкале юкка гына түгел: «Балачакта алган белем — ташка язган сүз белән бер», — ди. Шәһәребезнең татар активистлары арасында гаилә нәселен өйрәнү, гаиләнең шәҗәрәсен төзү тәҗрибәсе булган кешеләр табылса, татар мәдәнияте йортында факультативлар һәм семинарлар оештырылса шәп булыр иде. Мондый чаралар җитәкчеләребез һәм күп кенә татарлар тарафыннан ярдәмсез калмас дип ышанам.

**Рәфидә Исаева, Новосибирск өлкәсенең региональ татар мили-мәдәни автономиясе советы әгъзасы:**


— Мондый чарада икенче тапкыр катнашам. Һәрчак вакыйгаларның масштабы таң калдыра. Татарстан әлеге чараны уздыру өчен шактый көч һәм чыгымнар сарыф итте дип уйлыйм. Күпләр бирегә үз фикерләре һәм тәкъдимнәре белән килделәр. Һәркем үз өлкәсендә яңалык белергә тырышты. Васил Шәйхразыев һәрвакыттагыча биеклектә. Ул һәркемгә сүз бирде һәм тыңлады. Ишетелергә теләгәннәр — ишетелде. Бик күп кызыклы кешеләр белән таныштым. Равза Шамил кызы белән соңгы көнне ТР Мәдәният министрлыгында булдык. Анда мин эшмәкәрләр үз тәкъдимнәре белән мөрәҗәгать итә алуларын белдем. Һәм әлеге өлкәгә турыдан-туры караучы министрлык һәм башка ведомстволарның ярдәмен алырга мөмкин. Минем өлкә — туризм. Мин яшь татарларны үз өлкәмә җәлеп итү, яшәү урыннарында туристик компанияләр оештыру, әлеге кызыклы эш белән шөгыльләнү һәм алга этәрү идеясе белән яндым.

Бу чарага вакыт табып, шәһәремә яңа уйлар белән кайтуыма бик шат. Еш кына «Татарлар» видеоролигын кабат карыйм, күздән яшьләр чыга. Мин татар булуым белән горурланам!


***Дания БИСЕРОВА,***
***Таңсылу Галимова, съезда катнашучылар һәм автор фотолары***



*«Печән базары» ярминкәсе*



*Кабан күленең җәяүлеләр яры*



*Татар йортлары бигрәк матур!*

# СМЕНА РАСТЕТ

***С 5 по 14 августа прошла VII профильная детская смена «Милләтебез хәзинәләре Себер сандыгында» («Сокровища нации в Сибирском сундучке»). В 140 км от Новосибирска комфортабельная база отдыха «Зелёный Дом» вновь радушно приняла детей, подростков и взрослых новосибирцев. Ожидания участников смены на классный отдых, новые знакомства и полезные знания оправдались полностью. Итоговую точку в приключениях поставил VII Детский Сабантуй на подворье Дома татарской культуры.***

Если мероприятие удалось, значит, люди, которые его готовили, на самом деле переживали за результат и вложили в происходящее много сил, времени, умений и душевного тепла. Когда же речь идет о детской загородной смене — тематическом лагере на вольной воле, где нет мам-пап, а воспитанники хотят ходить на головах — ответственность и успех организаторов усиливаются стократно.



Конкурс «Татар кызы»

Вот они, отважные энтузиасты, кому родители и бабушки-дедушки доверили заботу о своих детях: методист Новосибирского областного татарского культурного центра (НОТКЦ), педагог по татарскому языку, специалист по национальным играм, культуре и традициям Рамзия Галиева; педагог по вокалу Детской студии татарского искусства при НОТКЦ Динара Сабирова; педагог по декоративно-прикладному творчеству, руководитель Детской студии татарского искусства при НОТКЦ Альсина Шаймарданова; педагог дополнительного образования и хореограф муниципального бюджетного учреждения дополнительного образования Новосибирска «Центр развития творчества детей и юношества «Заельцовский» Оксана Климченко; методист НОТКЦ и старшая вожатая Айсылу Нуралинова; вожатая младшего отряда и преподаватель по рисунку София Сабирова; вожатая старшего отряда Сабина Латфуллина.



На этом фото прекрасно все!

**И, конечно, директор НОТКЦ и идеолог смены «Милләтебез хәзинәләре Себер сандыгында» Равза Тихомирова:**

— Целых 10 дней мы провели с вашими замечательными детками. Это одна из лучших смен, недаром число 7 считается счастливым. О каждом ребенке можно не только очень много говорить — песни петь! Талантливы во всем! Мы постарались раскрыть потенциал детей и дать им возможность проявить себя как можно шире. Сегодня на нашем Детском Сабантуе вы увидите результаты, которых нам удалось достичь за время смены. Я еще раз хочу поблагодарить свой женский коллектив, педагогов и вожатых, которые все дни смены были едины, не чурались никакой работы, не спали ночами, готовили мероприятия, бережно и уважительно относились друг к другу и к деткам. Девочки! Всем большое спасибо — мы это сделали!



Перед выходом на сцену

За активное участие в работе профильной смены и популяризацию татарской культуры все педагоги и вожатые получили благодарственные письма татарских организаций Новосибирской области.

Профильную детскую смену «Милләтебез хәзинәләре Себер сандыгында» Новосибирский областной татарский культурный центр и ОО «Региональная Татарская Национально-Культурная Автономия Новосибирской области» организуют при поддержке молодежного центра «Идель». Цель — объединить на почве этнической самобытности, развития национального самосознания и родного языка детей из татарских и смешанных семей, проживающих в Новосибирской области.

Проект уже вырастил поколение молодых татар, для которых слова «родная культура» имеют принципиальное значение.

**Айсылу Нуралинова прошла путь от участницы смены «Милләтебез хәзинәләре Себер сандыгында» до старшей вожатой и методиста центра.**

— Я ездила на смену с 14 лет, сейчас мне 21. Смена всегда проходит позитивно и весело, каждый год к привычным конкурсам добавляются новые. Я выросла на татарской культуре, для меня это большая и необходимая часть жизни. То, что я поехала в «Зелёный Дом» как старшая вожатая в четвертый раз, оказалось очередным интересным опытом, потому что у современных детей есть чему учиться. Они очень развитые, инициативные, разносторонние. Чтобы каждый участник смены мог себя проявить в том, что умеет лучше всего, мы в этом году впервые провели большой конкурс талантов «Йолдызлар». Такой новый формат без строгих рамок. Дети показывали свою индивидуальность. Умеешь жонглировать? Пожалуйста. Хорошо поешь? Послушаем. Танцуешь, занимаешься гимнастикой, любишь читать, обладаешь задатками модели? Всем талантам зрители были рады и искренне поддерживали конкурсантов. Дети это чувствовали и не стеснялись, потому что на смене царит домашняя атмосфера. Все по-семейному просто, дисциплина поддерживается общими усилиями. Младшие слушают старших, а те, в свою очередь, не командуют, а просят. Мы старались сделать так, чтобы участники смены, когда вернутся домой, продолжили интересоваться татарской культурой. Педагоги и вожатые внедряли в бытовую лексику детей простые слова татарского языка, которые легко запомнить и использовать. Из 28 человек, младшему из которых 7 лет, несколько ребятишек были русскими. Но они, в итоге, заговорили и запели по-татарски, причем некоторые показали отличное произношение. Дети хотят движения, общения, новых впечатлений. Поэтому мы сделали флешмоб на песню Гузель Уразовой, чтобы дать выход энергии участников смены. Мы старались быть с детьми на одной волне, мне кажется, у нас получилось. В целом, мы старались сделать упор на изучение татарских национальных традиций, культуры, ведь в мире сейчас все смешалось, границы стерты. А нам хочется, чтобы каждый ребенок знал свои корни, гордился своей семьей, изучал родной язык.



Спасибо центру «Идель» за поддержку



Идет урок татарского языка

14 августа на Алейской, 16, прошел Детский Сабантуй.

Громкие аплодисменты зрителей сопровождали яркие концертные номера. Дети так хотели показать все, чему научились за 10 дней смены, что публика отбила ладони: каждый следующий артист старался выступить лучше предыдущего.

Поразительно, какой эффект дает совместное творчество одаренных детей и увлеченных педагогов. Слова восхищенных родителей в адрес коллектива НОТКЦ звучали на протяжении всего праздника.

**Екатерина Замай, мама Киры Бондаревой:**

— Наша семья выражает огромную благодарность педагогам татарского лагеря! Очень теплое отношение, насыщенная программа, прекрасное место, погода не подвела. За 10 дней столько успели — профессионализм налицо. Подумываю отправить ребенка в театральную студию, так как открылся талант. Очень ценно, что в детях воспитывают любовь к языку и традициям. Желаем творческих успехов, неиссякаемой энергии и сибирского здоровья!



Будущие жены и мамы

**Варвара Семёнова, мама Ульяны Семёновой:**

— Молодцы, делаете большое доброе дело! Хочу выразить благодарность татарскому центру за организацию детской смены. Я отправляла ребенка в «Зелёный Дом» первый раз, это вообще был первый лагерь в ее жизни, все очень понравилось! Мне кажется, такого разнообразия конкурсов, занятий мы бы даже в течение года не освоили. Педколлектив смены очень дружный, чувствуют каждого ребенка, все делается искренне. Мне было очень важно, чтобы дочь там не переживала, сохранила желание ездить еще. Первые дни привыкания Ульяне было сложновато, я писала Равзе Шамильевне и педагогам, они отнеслись с пониманием, поддерживали Ульяну, общались, смотрели, какое у нее настроение, психическое состояние. Все прошло очень здорово! На концерт мы звали одну девочку, которая тоже поехала в лагерь впервые, но в спортивный, и ей в гостях на татарской смене очень понравилось. Танцы, песни, каждый день бассейн, очень хорошее питание. Я на следующий год своего ребенка тоже с удовольствием отправлю.

**Радмир Рахматуллин, папа Марата Рахматуллина:**

— Искренняя родительская благодарность всему коллективу смены «Зелёного Дома». Мой сын был окружен заботой и вниманием, увлекательным погружением в татарскую культуру и незабываемую атмосферу семьи. Это чувствовалось во всем, в утренний зарядке, в изучении языка, в танцах, в творчестве. Отдельно благодарен Равзе Шамильевне за организацию смены и работу Новосибирского областного татарского культурного центра — большую творческую семью, объединенную любовью к детям, людям и татарской культуре. Профильная детская смена «Милләтебез хәзинәләре Себер сандыгында» не только обучает, сплачивает, но и всесторонне оздоравливает детей и подростков. Утренняя зарядка, бассейн, волейбол, походы в лес за грибами и ягодами для детей — настоящие удовольствия. Польза целебного хвойного воздуха в напряженном учебном году, который начнется совсем скоро, проявится еще не раз.

**Лилия Сиразетдинова, мама Альмиры и Ильнары Сиразетдиновых:**

— Хочу от всей души поблагодарить весь коллектив, который принимал участие в организации и проведении этой смены. Отличные педагоги! Прекрасная хореограф! Все-все, кто занимались нашими детьми целых 10 дней, заслуживают самого большого уважения. Дети очень довольны! Когда мы забирали их со смены, чтобы ехать домой в Юргу, в Кемеровскую область, они только сели в машину, как сразу сказали: «Мама, на следующий год мы поедем обязательно, нам очень-очень понравилось!» Всем большое спасибо от нашей семьи!




Момент Детского Сабантуя

*Виктория КУПЦОВА,*
*фото участников смены и автора*

# НАВЕСТИЛИ СОСЕДЕЙ

***5-7 августа историко-мемориальный комплекс «Искер» под Тобольском собрал на ежегодный фестиваль участников и гостей из более чем 20 регионов РФ и стран ближнего зарубежья. Приятно, что побывали там и представительницы нашей области.***



*Разия Хамидулина*

Август — горячая пора заготовок на зиму даже у городских хозяек, что уж говорить о сельских труженицах. Однако Разия Хамидулина — заведующая сельским ДК аула Кошкуль Чановского района и руководитель вокального дуэта «Миләшләр» — давно известна трепетным отношением к родной культуре и горячим желанием пропагандировать народное искусство татар. Тем понятнее ее желание поехать в Тобольск, чтобы принять участие в знаковом XIII Международном фестивале историко-культурного наследия сибирских татар «Искер-Җыен». Разия Хамидулина успешно выступила и привезла домой благодарственное письмо оргкомитета, дипломы участника в номинации «Художественное слово» и лауреата III степени в номинации «Вокал соло». Наша землячка вдохновилась на фестивале «Искер-Җыен» свежими впечатлениями и запасом позитивных эмоций. Значит, у «Миләшләр» скоро появятся новые прекрасные песни.

Жительница пос. Малый Тебис Чановского района Таскира Кусаинова тоже не смогла устоять перед притяжением Искера. Она побывала в Тобольске вместе с дочерью. Ближе познакомившись с мамой, понимаешь, в кого Дания выросла талантливой умницей и красавицей!

**Рассказывает Дания Кусаинова, член татарского молодежного клуба «Алтын йолдыз» при ГБУК НСО «НОТКЦ»:**

— Об «Искер-Җыене» мы с мамой узнали из интернета. Фестиваль историко-культурного наследия сибирских татар нам сразу стал интересен, потому что мы сами являемся сибирскими татарами. При подаче заявки увидели отметку, что требуются волонтеры, которые должны будут заехать на несколько дней раньше сроков проведения фестиваля. Долго не думая, решили поехать на это историческое место. На самом фестивале мы с мамой выступили в концертной программе, исполнили песню «Ак калфак», которую специально перевели на свой родной барабинский язык. Неожиданно для нас, наш дуэт «Тоёр» стал лауреатом I степени в номинации «Вокал дуэт». Помимо конкурсной программы, в рамках фестиваля проходила научно-практическая конференция. В ней участвовали ученые из России и Казахстана. Темы затрагивались самые разные, от периода правления хана Кучума до современных тенденций развития сибирских татар. В Тобольске и на Кучумовом городище из года в год под эгидой РТОО «Наследие» по Тюменской области (рук. Луиза Шамсутдинова) собираются неравнодушные общественники, представители официальных властей, духовенства, люди науки и искусства. Все в Тобольске желанные гости. Дискуссии выливаются подчас в горячие споры, но в словесных баталиях рождается истина. Практический опыт, дружеская атмосфера, новые знакомства — все было на «Искер-Җыене».



*Таскира и Дания Кусаиновы*

*Соб. инф.*

# ВКУСНО И ВЕСЕЛО!



*В каждом сердце — чәк-чәк!*

***23 августа в Доме татарской культуры состоялся I фестиваль татарской национальной кухни «Чәк-чәк бәйрәме». Для зрителей и участников праздника была подготовлена концертная программа с участием творческих коллективов ГБУК НСО «НОТКЦ», организованы площадки с татарскими народными играми, выставкой и мастер-классом по нарезке домашней лапши, который собрал немало желающих попробовать себя в этом деле.***

Кулинарное искусство татарского народа богато своими традициями. Наш народ бережно хранит секреты национальных блюд, передавая их из поколения в поколение. Татарскую кухню отличает обилие мучных изделий: кыстыбый, бәлеш, өчпочмак, кош теле — эти блюда, конечно же, никого не оставят равнодушным.

Но самым вкусным и любимым лакомством татар был и остается чәк-чәк.

Раньше он считался торжественным, праздничным угощением, вроде торта по особым случаям. Чәк-чәк присутствовал на всех значимых датах. На свадьбах родители молодых, навещая друг друга, приносили в качестве гостинцев пироги и непременно чәк-чәк.

Сейчас нам уже не нужен особый случай, чтобы приготовить чәк-чәк и порадовать себя и родных этой сладостью за чашечкой ароматного чая. Поэтому в рамках фестиваля прошел конкурс на самый лучший чәк-чәк. Конкурсантки к его приготовлению подошли творчески, оригинально украсили каждое блюдо, проявили фантазию и уважение к традициям. Стол с золотистыми блюдами выглядел аппетитно, жюри оценивало старания участниц по нескольким критериям: внешний вид, профессиональное мастерство и вкусовые качества.

Определить одну победительницу оказалось невозможно. Члены жюри: директор ГБУК НСО «Новосибирский областной татарский культурный центр» Равза Тихомирова, руководитель детской студии татарского искусства при ГБУК НСО «НОТКЦ» Альсина Шаймарданова и член ОО «РТНКАНО» Галия Кретова приняли решение вручить дипломы и памятные подарки в трех номинациях. *«Иң матур чәк-чәк»* — Эльзе Кочетовой; *«Иң тәмле чәк-чәк»*— Ясмине Абдрахмановой; *«Иң креатив чәк-чәк»* — Альбине Хамидулиной.



*Выступает Детская студия*



*Рамзия Галиева учит нарезке домашней лапши*

Гостям, которых на фестивале было очень много, супермаркет домашней еды «Бахетле» предложил попробовать фирменный чәк-чәк и кош теле. Угощали зрителей концерта Айсылу Нуралинова и София Сабирова.



*Члены жюри и победительницы*

**Параллельно с конкурсом на лучший чәк-чәк и концертом, здесь же, на открытом воздухе, проходил мастер-класс по нарезке домашней лапши-токмач. Вот что рассказала его ведущая, методист ГБУК НСО «НОТКЦ» Рамзия Галиева:**

— Мастерство хозяйки, конечно, видно во всем, но у татарских женщин умение тоненько-тоненько и аккуратно нарезать лапшу ценилось всегда. Домашний суп-лапша — наше старинное национальное блюдо, ему столько же лет, сколько живут на свете татары. Хозяйка обязана уметь вкусно его готовить! Где бы татары ни жили, они любят токмач. Лапша должна быть тонкая, чем тоньше, тем вкуснее. Как сделать нужное тесто (в нем только мука, соль и яйцо), правильно раскатать в пласт, каким ножом и как резать — хитростей множество! Я делюсь секретами со всеми!

Одной из многих желающих научиться красиво резать лапшу оказалась школьница Милана Комарова. На вопрос: «Кто у тебя в семье татарин?» ответила, что никто. С таким талантом к готовке (Рамзия-апа ее токмач похвалила) придется Милане со временем выйти за татарина замуж. Такая жена — на вес золота!

**8-летняя Сафина Усманова ходит в Детскую студию татарского искусства при ГБУК НСО «НОТКЦ» с 4-х лет. Она участвовала в концертной программе фестиваля «Чәк-чәк бәйрәме» и согласилась дать небольшое интервью:**

— Мне мама предложила пойти в Детскую студию, и я захотела попробовать. Мне понравилось! И мне до сих пор нравится! В Детской студии я учусь новому и много узнаю. Я учу татарский язык, татарские песни. Сегодня мы пели татарскую песню о нашей земле. От концертов и выступлений у меня прибавляются силы, я бы хоть каждый день хотела выступать. В Детской студии меня еще учат танцам и татарским культурам. Я становлюсь взрослее и умнее. Умнее потому, что я узнаю все больше слов татарского языка. Раньше я его не знала совсем, но сейчас уже знаю. Я могу вам сказать слова на татарском языке. Я обожаю чәк-чәк! Обожаю! За то, что это татарская сладость. Он такой вкусный!



*Угощает София Сабирова*

**О том, почему все люди, которые хоть раз в жизни попробовали чәк-чәк, навсегда в него влюбляются, рассказала одиннадцатиклассница София Сабирова, одна из ведущих фестиваля:**

— Чәк-чәк — самое известное татарское блюдо. Когда спрашиваешь любого человека, который совсем не татарин, какое он знает татарское блюдо, он скажет: чәк-чәк. Я сегодня пришла как волонтер на фестиваль, хочется рассказывать людям о том, что чәк-чәк — очень популярный десерт во всем мире потому, что он очень вкусный и полезный, там нет ничего искусственного, даже сахара. Там мед. Чәк-чәк продается почти во всех магазинах, но не такой, как домашний. Когда готовишь дома, ты знаешь, что нужно положить, чтобы получилось вкусно. Моя мама готовила его, я помогала, но сама делать не пробовала. Возможно, попробую, хотя это непросто. Когда мама готовит, я наблюдаю и учусь. Хочу научиться готовить хорошо.



*Равза Тихомирова*

Организаторами I фестиваля татарской национальной кухни «Чәк-чәк бәйрәме» стали: Министерство культуры Новосибирской области, ГБУК НСО «Новосибирский областной татарский культурный центр», ОО «Региональная Татарская Национально-Культурная Автономия Новосибирской области». Праздник получился очень душевным, зрители уходили довольными, много было сказано восторженных слов благодарности! Надеемся, что на следующий год наш фестиваль соберет еще больше участников и зрителей.

*Дина ФАЙЗУЛИНА, методист ГБУК НСО «НОТКЦ», фото Виктории КУПЦОВОЙ*

Газета выходит при поддержке ОО «РТНКАНО» и ГБУК НСО «НОТКЦ», г. Новосибирск. Наш сайт: www.tatar.nso.ru, инстаграм: @tatar_nsk
Главный редактор: Виктория КУПЦОВА, +7 953 795 10 08, e-mail: vikki7019@yandex.ru. Выпускающий редактор: Ралия ГАЛЕЕВА. Корректор: Дания БИСЕРОВА. Редакционная коллегия: Амир ГАРЕЕВ, Равза ТИХОМИРОВА. Компьютерный дизайн и верстка: Ралия ГАЛЕЕВА. Адрес редакции: 630015, г. Новосибирск, ул. Алейская, 16, тел.209-10-47. Газета отпечатана в типографии "Печатный дом-НСК", г. Новосибирск, ул. Лазарева, 33/1. Подписано в печать 31.08.2022 г. Тираж: 999 экз.